Теләче районы Югары Кибәхуҗа

урта гомуми белем бирү мәктәбенең

Ю.А.Гагарин исемендәге балалар оешмасының

# ЭШЧӘНЛЕК ПРОГРАММАСЫ

Эчтәлек

1. Аңлатма язуы ........................................................................ 2

2. Максат һәм бурычлар .................................................................. 3

3. Программаны тормышка ашыру ысуллары........................... 4

4. Программаны тормышка ашыруда катнашучылар............. 5

5. Тормышка ашыру сроклары .......................................................5

6. Программаның структурасы........................................................5

7. Юнәлешләре буенча эчтәлеге......................................................6

8. Календарь-тематик планлаштыру...............................................7

9. Йомгаклау (көтеп алган нәтиҗәләр)...........................................12

10. Кулланылган әдәбият....................................................................18

11. Кушымталар...................................................................................18

Аңлатма язуы

Балалык еллары һәркем тормышында шәхес буларак үсеш чоры. Балачакта һәркем файдалы эштә катнашырга , яшьтәшләре белән тиешле дәрәҗәдә аралашырга, коллективта үзен күрсәтә, танылырга омтыла. Тәрбия эше бервакытта да җиңел бирелми. Бүгенге көндә бу аеруча актуаль мәсьәлә. Хәзер барлык көчебезне балалар тәрбияләүгә куярга тиешбез. Кызлар һәм малайларның төрле оешмаларга берләшеп, файдалы эшчәнлек алып барулары табигый хәл. Һәр бала үзенчә сәләтле, талантлы. Баланың бирелгән сәләте тулысынча ачылсын өчен акыллы оештыручы кирәк. Балалар оешмалары - иҗтимагый тормыш мәктәбе ул. Анда катнашу һәм вакытны файдалы, кызыклы итеп үткәрергә, шәхес буларак танылырга ярдәм итә.Үз оешмаларында балалар демократиягә һәм хәбәрдарлыкка, башкаларны инандырырга, кирәкле фикерләрне тыңлый белергә, активлыкны күрсәтергә, уңай традицияләрне сакларга, яңаларын барлыкка китерергә өйрәнәләр. Әлеге программада Миннегали Ногманов исемендәге балалар оешмасының ук эшчәнлеге чагыла. Программа 1 елга (2016-2017 нчы уку елына) төзелде. Программаның төп үзенчәлеге : балаларның яшь үзенчәлекләрен , мөмкинлекләрен исәпкә алу. Балаларның кызыклы, файдалы тормыш белән яшәвенә аларның кечкенәдән инсафлы, әдәпле булып үсүләренә ирешү – төп бурычның берсе.. Оешмада башкарыла торган эшләр мөстәкыйльлеккә, ирекле аралашуга, сәләтеңне үстерергә өйрәтә. Уку елы башында без президент сайлаулары үткәрәбез. 7-10 сыйныфлардан президентка кандидатлар күрсәтелә, тавыш бирү хисабына сайлап куела һәм 3 ел буена эшли. Укучылар җыеннарында үзенең программасы белән таныштыра. Оешма 10 отрядны үз эченә ала. Һәр отрядның җитәкчесе һәм ярдәмчеләре билгеләп куела. Уку елы дәвамында балалар оешмасы бик күп эшләр эшли. Укучыларны яшь үзенчәлекләренә карап өч төркемгә бүләбез. Эзтабарлар берлеге - 8 (3 отряд 1,2, ,4 сыйныфлар) Варислар берлеге - 28 ( 4 отряд 5,6,7,8 сыйныфлар) Укучылар үзидарәсе 15 ( 3группа 9,10,11 сыйныфлар) Балалар оешмасы “Эзтабар юлдашы”, “Мирас юлы” , “Галстуклылар иле”, “Сыйныф бердәмлеге” программалары буенча төрле юнәлештә эш алып бара. Бу программаларга таянып балалар үзләренең күптөрле кызыксынуларын тормышка ашыралар, яхшы булырга, кыенлыкларны җиңәргә өйрәнәләр. Балалар ялын оештыруның төп максаты да, балаларның укудан тыш вакытларын файдалы һәм кызыклы итеп үткәрүгә юнәлдерелгән. Куйган максатыбызга ирешү өчен балалар ялын оештыруны 5 юнәлештән чыгып алып барабыз: - танып-белү юнәлеше. Патриотик тәрбия бирү. - уку эшчәнлеге - культура-масса эше - хезмәт эшчәнлеге һәм тимурчылык - спорт эшчәнлеге Балалар оешмасы эшчәнлегенең максаты: - һәр балага күңеленә ятышлы нинди дә булса бер өлкәдә үз сәләтен нәтижәлерәк файдалану мөмкинлеге тудыру, яшьтәшләре белән ярдәмләшеп эшләвен тәэмин итү, укучыларның иҗади активлыгын үстерү; -мөмкин кадәр күбрәк

укучыны оешманың эшенә, планлаштыруга һәм чараларга, уен- конкурсларга, ярышларга тартып баланы шәхес буларак үстерү; -мөстәкыйль эшләргә өйрәтү; -бер-берсенә, өлкәннәргә, кечкенәләргә хөрмәт тәрбияләү, үзара дуслык булдыру.

**Төп бурычлар:**

1. Оешма эшенә барлык укучыларны да катнаштыру.

2. Оешманың күмәк эшләре аша балаларның әйләнә -тирәне танып белүләренә һәм анда үзләренең урыннарын табуга ирешү.

3. Оешма эшен, уеннар оештыруда мөмкин кадәр күбрәк укучыларны тарту. 4. Балаларның практик осталыкларын арттыру.

5. Балаларны иҗади һәм мөстәкыйль эшләргә өйрәтү.

6. Дөрес ял итәргә, буш вакытларын дөрес үткәрергә ярдәм итү.

7. Уен эшчәнлеге аша балаларның яхшы сыйфатларын, сәләтләрен ачыклау. 8. Үзләренең һәм иптәшләренең уңышларын дөрес бәяләргә, бер – берсенә ярдәм итәргә өйрәтү.

9. Үз исеменең кадерен белү, оешманың абруен саклау.

**Программаны тормышка ашыру ысуллары**

**Тәрбияләү ысуллары**: • укучылар үзидарәсе киңәшмәләре; • әңгәмә, балаларны актив иҗади эшчәнлеккә тарту; • эш-гамәлләрен дөресләп бару;

**Укыту ысуллары**: • Аңлатулы; • стимул бирә торган; • мәгълүмати- белдерүле. Эш формалары - сборлар - әңгәмәләр - кичәләр - конкурслар - пресс- конференцияләр - эзләнүләр - презентация - концертлар - күргәзмәлекләр - ярминкәләр

**Программаны тормышка ашыруда катнашучылар:**

Педагог-организатор, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, сыйныф җитәкчеләре, укучылар үзидарәсе, 1-11 сыйныф укучылары, әти-әниләр.

**Тормышка ашыру сроклары**: 2016-2017 уку елы (сентябрь- июнь)

**Программаның структурасы**:

**I бүлек - Әхлакый - танып белү юнәлеше. Патриотик тәрбия бирү.**

**II бүлек - Уку эшчәнлеге**

**III бүлек - Культура-масса эше .**

**IV бүлек - Хезмәт эшчәнлеге һәм тимурчылык**

**V бүлек - Спорт эшчәнлеге**

**Оешманың традицион чаралары:**

1сентябрь – Белем көне

15 сентябрь –ТВБ туган көне

1 октябрь- Өлкәннәр көне

5 октябрь- Укытучылар көне Көзге бал Шаяннар һәм тапкырлар бәйрәме Сөмбелә бәйрәме Уңыш бәйрәме Яңа ел

9 декабрь –Ватан геройлары көне

14 гыйнварь –Искечә Яңа ел

14 февраль- Гашыйклар көне

23 февраль- Ватанны саклаучылар көне

8 март - Халыкара хатын – кызлар көне

1апрель- Көлке көне

7 апрель- Сәламәтлек көне

9май – Җиңү көне

19май –Пионерия туган көн

25май – Соңгы звонок

**Программаның юнәлешләре буенча эчтәлеге**

**I бүлек - әхлакый - танып белү юнәлеше. Патриотик тәрбия бирү.**

1. Укучылар өчен кагыйдәләрне, мәктәп Уставын, балалар оешмасының Уставын өйрәнү.

2. Хокук бозуларга каршы профилактик эшләр.

3. Мәктәп буенча дежур тору.

4. Укучылар активы, вожатыйлар белән эш.

5. Отряд, дружина сборлары үткәрү.

6. Оешма газетасын чыгарып бару.

7. Отряд почмакларын эшләү.

8. Балалар газет-журналларына язылу. Укучыларның язмаларын газета битләрендә урнаштыру.

9. Патриотик чаралар үткәрү.

**II бүлек - уку эшчәнлеге**

1. Өлгереш экранын алып бара һәм начар өлгерүче классларга рейдлар ясау. 2. Уку комиссиясен сайлау.

3. Фән олимпиадаларын оештыру.

4. Китапханә белән берлектә эш оештыру, китапларны төзәтү эшләре.

5. Отрядлар арасында балалар оешмасының эшчәнлеген күрсәтүче рейтинг экранын булдыру.

6. Оешма эшчәнлегендә Сингапур структураларын куллану.

**III бүлек - хезмәт эшчәнлеге һәм тимурчылык**

1. Тимурчылык эшен оештыру.

2. Мәктәп территориясен төзекләндерүдә, мәктәп яны бакчасында эшләү. 3.Генераль җыештыру һәм дежур торуны оештыру.

4. Җиһазларның сакланышы һәм кабинетлардагы яшеллек учетын алып бару. 5. Обелискны чистартып тору.

**IV бүлек – культура –масса эше**

1. Ял кичәләре, концертлар, тематик кичәләр, тәрбияви дискотекалар үткәрү. 2. Конкурслар һәм смотрларга әзерлек.

3. Сәнгать бәйгеләрен үткәрү һәм катнашу.

4. Тәрбияви чаралар үткәрү.

**V бүлек - спорт эшчәнлеге**

1. Сәламәтлек көнен үткәрүне оештыру.

2. Кабинетларның санитар торышын тикшерү.

3. Наркомания, токсикомания, алкоголизм , тәмәке тартуны кисәтү буенча профилактик эш алып бару.

4. Физкульт минуткалар, тәнәфес вакытында күңелле уеннар оештыру.

5. Мәктәп күләмендә спорт ярышлары, спорт чаралары үткәрү.

## Календарь-тематик планлаштыру

***Уку юнәлеше*.**

**Максат: - Укучыларның ял вакытын файдалы һәм мавыктыргыч итеп үткәрү**

- **Укучыларда үз яшьтәшләре һәм өлкән буын вәкилләре белән аралашу күнекмәләрен үстерү**
- **Мәдәни, рухи, эстетик яктан үсешне тәэмин итү**

**Бурычлар:**

**-укучыларның ял вакытын файдалы итеп үткәрүнең асылына төшендерү**
**-балаларның талантын, сәләтен үстерүдә актив эш алып бару**

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Вожатыйлар укуы | Чиреккә бер | Педагог – организатор |
| 2. | Фән айлыкларында катнашу. | Ел буе | Педагог – организатор<br>Класс җитәкчеләре |
| 3. | Үз – үзенне әдәпле тоту дәресләре үткәрү. | Чиреккә бер | ЗДВР |
| 4. | Дружина эшчәнлеге белән танышу.( Айлык эшкә нәтиҗә) | Айга бер | Педагог – организатор |
| 5. | Район күләм олимпиадаларда катнашу. | Ел буе | Фән укытучылары. |
| 6. | Укучыларны этика- санитария кагыйдәләре белән таныштыру. | Чиреккә бер | Педагог – организатор |
| 7. | Укучыларны эчке тәртип кагыйдәләре белән таныштыру. | Чиреккә бер. | Педагог – организатор, ЗДВР |
| 8 | Дума җыелышы ( планнар белән танышу, эшләгән эшкә отчет ) | Чиреккә бер | ЗДВР |
| 9 | Атналык укуга нәтиҗә: йөреш , өлгереш . | Һәр шимбә | Педагог – организатор |

**Танып белү юнәлеше**

**Максат: - Белем һәм танып белү эшчәнлеге аша укучыларны киләчәк тормышка әзерләү, укучының тирә-юньне өйрәнү сәләтен үстерергә, кеше белән аралашырга өйрәтү .Яшь буында әхлак нормалары**

**формалаштыру, гражданлык активлыгын  үстерү. Югары әхлакый хокукка ия шәхес булып үсәргә ярдәм итү.**

**Бурычлар:**

**-төрле өлкә кешеләренең эшчәнлеге белән таныштыру**
**-укучыларның  сәләтен ачуга омтылышны арттыру**
**-хокукый аң тәрбияләү**
**-укучыларның тәртибен юридик нормалар күрсәтмәләренә туры килерлек   итеп корырга ярдәм итү**

| № | Эш төре | Вакыты | Жаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Отрядларда  сбор  үткәрү<br>“ Безне бөек эшләр көтә” – 5 кл. ,<br>“ Минем яраткан һөнәрем ”-6 кл , “Ярдәмләшеп яшик”- 7 кл ,<br>“ Сәламәтлек зур байлык ”- барлык классларда да . | Айга  бер | Педагог – организатор<br>Дружина советы рәисе – Мубаракзянова Ф. -10 класс укучысы |
| 2. | Дружина сборы үткәрү<br>“ Туган көнең котлы булсын” , “Без инде зурлар” | Ярты елга  бер | Педагог – организатор |
| 3. | Муса Җәлил туган көнне билгеләп  үтү. (Әдәби кичә) | 15 Февраль | Татар теле укуытучылары |
| 4 | “ Безне бөек эшләр көтә”  5 сыйныфта сбор | 15 Сентябрь | Педагог – организатор |
| 5. | «Хәтер көнен» билгеләп  үтү.<br>( кичә) | Октябрь | Педагог – организатор |
| 6 | Өлкәннәр  көне. ( әдәби кичә) | Октябрь | Педагог – организатор, ЗДВР |
| 7 | “Әниләр көне” үткәрү. ( әдәби кичә) | Ноябрь | Педагог – организатор |
| 8 | Бөтендөнья СПИДка каршы көрәш көнен билгеләп үтү. ( әңгәмә) | Декаберь | ЗДВР |
| 9 | “Ватанны саклаучылар” көнен үткәрү.  (Әдәби кичә) | Февраль | Педагог – организатор, |
| 10 | Очрашу  кичәсе (Әдәби кичә) | Февраль | ЗДВР |
| 11 | “Туган тел” кичәсе үткәрү. | Февраль | Татар теле укытучылары. |
| 12 | Театр көнен билгеләп үтү. (кичә) | Март | Класс җитәкчеләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | Сәламәтлек көнен билгеләп үтү. | Апрель | Класс җитәкчеләре. |
| 9 | Космонавтика көнен билгеләп үтү. ( рәсем конкурсы ) | Апрель | Рәсем укытучылары |
| 10. | Тылда хезмәт иткән әбиләргә булышу. | Ел буе | Педагог – организатор, Варис класслар. |
| 11 | 7 апрель –“Спорт – сәламәтлек” көненә . (Рәсем конкурсы) | Апрель | Педагог – организатор, |
| 12 | Г. Тукай туган көнне билгеләп үтү. (Экскурсия) | Апрель | Педагог – организатор, |
| 13 | Яшьләр көнен билгеләп үтү.<br><br>( Кичә) | Апрель | Класс җитәкчеләре. |
| 13 | "Гаилә" көнен билгеләп үтү.<br><br>( Гаилә бәйрәме үткәрү) | Май | Педагог – организатор, ЗДВР |
| 14 | Вафат булган ветераннарнын каберләрен чистарту. | Сентябрь , май. | Педагог – организатор, Укучылар үзидарәсе членнары |
| 15 | Ветераннар белән очрашулар үткәрү. ( Әдәби кичә) | 7-8 Май | Педагог – организатор, |
| 18 | Наркоманиягә каршы көрәш көне. ( рәсем конкурсы) | Июнь | ЗДВР |

**Хезмәт юнәлеше**

**Максат: - Хезмәт юнәлеше буенча эшне оештыру**

**-Укучыларда хезмәткә карата хөрмәт тәрбияләү**

**- Ярдәмчеллек сыйфатларын ныгыту**

**- Куркынычсызлык кагыйдәләрен саклау**
**Бурычлар:**
**-план нигезендә эшне башкару**
**-укучыларда хезмәткә карашны үстерү**
**-хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү**

| № | Эш төре | Вакыты | Жаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Ялгыз әбиләргә булышу. | Ел буе | Педагог – организатор, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 6 сыйныф укучысы – Мингазова Г. |
| 2. | Мәктәп бакчасында агач утырту, чистарту,чүп үләннәреннән<br><br>арындыру | Сентябрь –октябрь, май. | Педагог – организатор,<br><br>класс җитәкчеләре |
| 3. | Макулатура җыю | Октябрь | Педагог – организатор |
| 4. | Нарат күркәсе җыю. | Октябрь | Педагог – организатор |
| 5. | Китап , дәфтәрләрнең чисталыгын тикшерү. | Айга бер | Педагог – организатор |
| 6. | Өмәләрдә катнашу. | Чиреккә бер | Педагог – организатор |
| 7. | Мәктәп чисталыгын тикшерү. | Ел буе | Дежур укытучы.<br><br>Педагог – организатор |
| 8 | Мәктәп күләмендә дежур тору. | Ел буе | Дежур укытучы. |
| 9 | Нарат бөресе җыю | Май | Педагог – организатор |
| 10 | Дару үләннәре җыю, районга тапшыру | Ел буе | Педагог – организатор |
| | | | |

***Мәдәният юнәлеше.***

**Максат: - Белем һәм танып белү эшчәнлеге аша укучыларны киләчәк тормышка әзерләү, укучының тирә-юньне өйрәнү сәләтен үстерергә, кеше белән аралашырга өйрәтү**

**Бурычлар:**

**-төрле өлкә кешеләренең эшчәнлеге белән таныштыру**

**-укучыларның сәләтен ачуга омтылышны арттыру**

| № | Эш торе | Вакыты | Жаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | « Белем бәйрәме» ( әдәби кичә) | 1 -Сентябрь | Педагог – организатор, |
| 2. | «Көзге бал» кичәсе уткәрү. ( кичә) | Сентябрь | Педагог – организатор, |
| 3 | “Куркынычсызлык тәгәрмәче” (район күләм | Сентябрь | Физ-ра укытучысы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ярыш ) | | |
| 4 | “ Сез иң гүзәл кеше икәнсез”  (Әдәби кичә) | Октябрь | Педагог – организатор |
| 5 | “ Сезнең тормыш үзе батырлык” (өлкәннәр көненә  әдәби кичә) | Октябрь | Педагог – организатор |
| 6. | «Котлы булсын, Яңа ел!» кичә үткәрү | Декабрь | Педагог – организатор, ЗДВР |
| 7. | «Булдыклы егетләр» кичәсе  уткәрү | Февраль | Педагог – организатор, Физ-ра укытучысы |
| 8. | «Кояш гомере телим мин, әнием сиңа»  кичә үткәрү | Март | Педагог – организатор |
| 9. | «Озын  толым» кичәсе үткәрү | Март | ЗДВР |
| 10 | «Нәүрүз» бәйрәме  (кичә) | Апрель | Педагог – организатор |
| 11 | 1 май бәйрәме үткәрү. | Май | Класс җитәкчеләре. |
| 12 | «Жиңү безгә җиңел  бирелмәде»  (кичә үткәрү ) | Май | Педагог – организатор |
| 13. | «Сау бул  мәктәп –безне юл көтә» кичә | Май | Педагог – организатор |
| 14 | «Минем яраткан укытучым» - рәсем конкурсы | сентябрь | Педагог – организатор, рәсем укытучылары |
| 15 | "Я –гражданин  России”  ( рәсем конкурсы ) | Январь | Педагог – организатор |
| 16. | «Сәламәтлек -иң зур байлык» театр айлыгында катнашу | Февраль | Педагог – организатор |
| 17 | «Настоящие парни» спортивная игра | Сентябрь | Педагог – организатор, Физ-ра укытучысы |
| 18 | “Алтын каләм» конкурсында  катнашу. ( инша конкурсы) | Апрель | Педагог – организатор |
| 19 | «Балалар жыр һәм бию» фестивале. ( мәктәп күләм) | Ноябрь -декабрь | Педагог – организатор, җыр укытучысы |
| 20 | Фестиваль: «Йолдызлык» | Ноябрь | Педагог – организатор, җыр укытучысы |
| 21 | “ Тукай эзләре буйлап” поход | Март | Педагог – организатор |
| 22 | “Яхшылык кыл” акциясендә катнашу | Февраль | Педагог – организатор |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 23 | “ Замечательный вожатый” | Март | Педагог – организатор, ЗДВР |
| 24 | «Минем яраткан укытучым» - шигырь конкурсы | Сентябрь | Педагог – организатор, рәсем укытучылары |

# Йомгаклау ( көтеп алган нәтиҗәләр)

**Мәдәният юнәлеше.**

**Бурыч: Мәктәп һәм район күләмендә оештырылган фестиваль -конкурсларда актив катнашу.**

Мәдәния юнәлеше буенча мәктәптә бик күп эшләр башкарылды:” Белем бәйрәме” – 11 укучы катнашты . Бәйрәмгә укучылар әзерлек белән килгәннәр иде. Әти - әниләр, район вәкилләре , колхоз җитәкчеләре үзләренең теләкләрен , истәлекле бүләкләрен нәни дусдарыбызга тапшырдылар. Өлкәннәр көненә “ Өлкәннәрне хөрмәт итик” дигән темага укучылар чыгыш ясады. “Укытучым минем”, “Уңыш бәйрәме”, “Көзге бал”, “Яңа елда –кунакта”, “ Әти - әни , мин тату гаилә” гаилә бәйрәме зур әзерлек белән үтте. Бөек Җиңүнең 70 еллыгына тирән эчтәлекле стенд, тыл ветераннары турында китап чыгарылды. . “ Хуш киләсең Яңа ел!”, “Әниләр көне” кичәләре әти - әниләр һәм тамашачылар тарафыннан уңай бәяләнде.

Халыкара Туган тел көненә багышланган әдәби – музыкаль иртә үткәрелде, анда 8, 9 класс укучылары катнашты.

“23 февраль- Ватанны саклаучылар көне” уңаеннан “ Ягез әле, егетләр!” , “ Күңелле стартлар” уены оештырылды. “ Кошлар көне”, “ 8 – март” бәйрәме, “Гашыйклар көне”, “Сабантуй “ “Соңгы кынгырау”, башлангыч сыйныфлар арасында “Спорт гаиләсе “бәйрәмнәре үткәрелде, стена газеталары чыгарылды. Муса Җәлилнең , Габдулла Тукайның туган көннәренә багышланган иртәләр аерым план нигезендә үткәрелде. Укучылар белән “Актив года “ акциясендә катнашып – 3 урынга лаек булдык.

**Нәтиҗә**: Сәләтле укучыларга игътибарны көчәйтергә, сәләтләрен үстерү өстендә нәтиҗәле эш алып барырга.

**Әхлакый – танып белү юнәлеше**

**Бурыч: Әхлакый сыйфатлар турында даими сөйләшүләр алып бару, укучыларның әхлаклылык сыйфатларын үстерү.**

2016– 2017 уку елында әхлакый танып белү юнәлеше буенча 15 сентябрь Татарстан Варислар туган көн уңаеннан сбор үткәрелде. “ Без –эзтабарлар” 1 сыйныф укучыларын – Эзтабарлар берлегенә кабул итү сборында 23 укучы катнашты. Пионерия туган көнне мәктәп күләмендә 5 сыйныф укучыларын Татарстан Варислар берлегенә кабул итү сборында 39 укучы катнашты.

Башлангыч сыйныф укучылары белән Бөек шагыйрь Габдулла Тукай музеена сәяхәткә бардык. Укучыларга сәяхәт бик охшады. Алар үзләренә бик күп кирәкле мәгълүмат алдылар.

Өлкән класс укучылары белән профессия сайлау турында әңгәмәләр, профотряд сборлары үткәрелде.

Авыл фельдшерлары белән “ Сәламәтлек” темасына сөйләшүләр алып барылды. Һәр отрядта “ Сәламәтлек –зур байлык, Сәламәт булыйк, Сәламәт тәндә- сәламәт акыл” дигән темаларга сборлар үткәрледе.

7 аперль – сәламәтлек көне аерым план нигезендә үтте.

**Нәтиҗә:** Укучыларның сборларга йөрешенә нык игътибар итәргә.

**Спорт юнәлеше.**

**Бурыч: Балаларның сәламәтлеген ныгыту максатыннан спорт чаралары оештырырга, актив катнашырга.**

“ Сәламәт тәндә- сәламәт акыл” дигән темага һәр класста тәрбия дәресләре үткәрелде. Һәр көнне дәрес башланырга15 минут кала сәләмәтлек дәресләре үткәрелде. Февраль аенда спорт атналыгы үтте.

“ Куркынычсызлык тәгәрмәче” исеме астында спорт ярышларында катнашып призлы урыннар алдык. Волейбол, Баскетбол , футбол ярышларында актив катнаштык.Көзге , кышкы, язгы спартакиадада катнаштык. “Ягез әле, егетләр”, “Спорт гаиләсе” бәйгеләре әзерлекле , тирән эчтәлекле үтте. Укычылар район күләмендә үткәрелгән “Кул көрәше” ярышында актив катнашып призлы урынга лаек булдылар.

**Нәтиҗә:** Төрле чаралар аша укучыларда спортка карата кызыксыну уятырга.

**Хезмәт юнәлеше.**

**Бурыч: Укучыларны иҗади хезмәттәшлеккә тарту, хезмәткә уңай караш тәрбияләү.**

2015 – 2016 уку елында түбәндәге эшләр эшләнелде. Тимурчылык штабы ялгыз әбиләргә ярдәм итү, хәлләрен белү, су ташу, кар көрәү, эшләрен эшләделәр. Туган колхозыбызга бәрәңге алуда булыштылар. Сугышта вафат булган ветераннарның каберләрен чистарттылар . Укучылар көл җыю өмәсендә дә актив катнаштылар. Мәктәп бакчасында оештырылган өмәләрлдә укучылар актив катнаштылар.

Мәктәп күләмендә рәсем конкурслары оештырылды. Һәр сыйныфта әдәплелек, өлкәннәргә һәм ятимнәргә ярдәм итүгә багышланган темалар астында тәрбия дәресләре ( “ Минем яраткан укытучым”, “Укытучы гаиләсе ”, “Ягымлы сүз”, “Безнең тату гаилә” , “Спорт гаиләсе”һ.б.) үткәрелде.

“Спорт гаиләсе” акциясе мәктәптә бик оешкан төстә башланып китте. Югары Кибәхуҗа урта мәктәбендә әлеге тема астында күп кенә эшләр эшләнде. Югары Кибәхуҗа һәм Максабаш авылларындагы ярдәмгә мохтаҗ әби-бабайларны барлап, һәрберсенә берәр класс беркетелде. Сугыш һәм тыл ветераннарына, өлкән яшьтәге һәм ялгыз яшәүче кешеләргә укучылар актив рәвештә ярдәм итәләр. Өй һәм каралты тирәсендә кар көрәү, өй җыештыру, кибеттән ризык алып кайту һәм башка кушылган эшләрне башкаралар. Максабаш авылында ялгыз яшәүче Нигматзянова Хәнүзә апага 9 сыйныф укучылары утын әзерләүдә булыштылар.

Уку елы башында укучылар кышлаучы кошларга җимлекләр ясап элгән булсалар, яз җиткәч җылы яктан кайтучы кошларга оялар ясап элделәр.

Май аенда укучылар ярдәмендә сугыш һәм тыл ветераннарының каберлекләре чистартылды.

Җиңү бәйрәмендә сугыш һәм тыл ветераннары каршында бәйрәм концерты оештырылды.

Укучылар берлеккә кергәндә үк Варисларның законнарын төгәл үтәргә дип сүз биргәннәр иде. Оешманың өченче законы : “Варис – тугрылыклы иптәш, олыларга һәм кечкенәләргә булыша, беркемне дә авырлыкларда ялгыз калдырмый”,-дип өйрәтә. Ягымлы сүз дөньяны яктырак һәм шәфкатьлерәк итә. Мәрхәмәтле эшләр ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә кирәк ул. Әгәр башкаларның сиңа мөнәсәбәте әйбәт булуын теләсәң, үзең дә аларга карата рәхимле бул! Шуңа күрә варислар

авыруларга, гарипләргә, ялгыз картларга һәм ярдәмгә мохтаҗ сабыйларга һәрвакытта да ярдәм кулы сузалар. Укучылар игелеклелек традициясенә таянып эш алып баралар.

5 сыйныфлар – Суфия , 6 сыйныфлар – Хасанова Мәрьямбикә , 7 сыйныфлар - Халисә әбиләргә булышалар. Алар атнага 2 тапкыр : сишәмбе, җомга көннәрендә баралар. Укучылар : Өй һәм каралты –кура тирәсендәге карларны көрәү, өй җыештыру, су китерү, кибеттән кирәк әйберне алып кайту, идән себерү, тузан сөртү, утын кисү, яру, кертеп урнаштыру эшләрен башкардылар.

Укучылар мәктәп һәм район күләмендә үткәрелгән олимпиадаларда катнаштылар. Күп кенә укучылар призлы урыннар алдылар. Мәсәлән, Исламов Ф., Хазиева А. , Афзалова Ә. Укытучылар: Ибраева Р.З., Мифтахова С.Г. , Низамутдинова В.А.

**Нәтиҗә**: Сәләтле укучыларга игътибарны көчәйтергә, сәләтләрен үстерү өстендә нәтиҗәле алып барырга.

## Кулланылган әдәбият:

1. “Галстуклылар иле” программасы

2. Новое о теории и методах работы с детскими организациями

3. “Мирас юлы” программасы

4. “Эзтабар юлдашы” программасы

5. “Класс бердәмлеге” программасы

6. Мин бәйрәмнәр ятатам. К.В.Закирова. Татарстан китап нәшрияты. 2009.

7. Онытылмас мәктәп еллары. Казан.2005.

8.Бәйрәмнәр бәйләме. “Мәгариф” нәшрияты.2005.

9. Хәерле көн, укытучы! Казан. 2004.

10. Көмеш тарак. Галимҗан Гыйлманов. Татарстан китап нәшрияты. 2000.

11. Могҗизалы мәктәп сәхнәсе. “Мәгариф” нәшрияты. 2003.